БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» 04 2022 ел № 179

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын раслау турында

«Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле үзидарә бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын раслау турында» 2021 елның 30 декабрендәге 1345 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын расларга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы һәм Балтач муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисләренә йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «27» 04
179 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә
үзгәрешләр кертү тәртибе һәм вакытлары

Әлеге Тәртип «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле үзидарә бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле үзидарә бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләренең 10 пункты, «Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын раслау турында» 2021 елның 30 декабрендәге 1345 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә (алга таба тиешенчә - исемлек, баш администратор) үзгәрешләр кертү механизмын һәм вакытларын билгели.

Баш администраторларның составы һәм (яки) функцияләре үзгәргәндә, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәре классификациясенең кодларын билгеләү һәм бирү принциплары үзгәргәндә, исемлеккә үзгәрешләр, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетының керемнәрен классификацияләү кодларының баш администраторларына беркетелгән составына үзгәрешләр Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы боерыгы нигезендә, «Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2021 елның 9 декабрендәге 378 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертмичә генә кертелә.

Федераль һәм региональ законнарга бюджет керемнәрен классификацияләү кодларының баш администраторларына беркетелгән составына үзгәрешләр кертү өлешенә үзгәрешләр кертелгән саен Исемлеккә үзгәрешләр кертелә.